


Укытучы  - авыр, катлаулы, кирәкле, шул ук вакытта ин гvзәл, һонәрләрнен берсе. Укытучы һонәре - чын мәгънәсендә барлык һонәрләрнен анасы. Шуна кvрә бу  һонәрне сайлаган кеше гажәеп дәрәжәдә тәрбияле, гыйлемле булырга тиеш.  Шулай сvзебез Кадошкино районы Латышовка урта мәктәбендә татар теле һәм  әдәбияты буенча киләчәк буынга белем бирvче Светлана Равил кызы Поташова  турында. Ул vзенен чын укытучы исемен чираттагы тапкыр дәлилли.
Мордовия  республикасында гына тvгел, еш кына Татарстанда оеш-тырылган чараларда укучылары, укытучы vзе лаеклы беренче, яки призлы урыннар яулыйлар. Быел  әлеге укытучынын укучылары татар теле һәм татар әдәбияты буенча  регионара олимпиадасында алдынгылар булса, vзе - Казанда татар теле  укытучылары очен махсус оештырылган Ботенроссия конкурсында жинvчеләрнен  берсе нәкъ Кадошкино районы Латышовка урта мәктәбе укытучысы Светлана  Равил кызы Поташова булды. Анын унышлы катнашуы мәктәбе очен дә,  Мордовиянен, Татарстаннын ботен мәгариф системасы очен дә моһим  вакыйгага әйләнгән.

Светлана Равил кызы конкурста укучыларга белем биреп кенә калмыйча,  туган телне ойрәнvгә кызыксыну уятучы инновацион укыту методикаларын  кулланучыларнын берсе буларак педагогик тәжрибәсе белән чыгыш ясаган. Ул  заманча технологияләр һәм интерактив методлар кертеп белем бирv  процессын мәгълvмати гына тvгел, мавыктыргыч та итә. Анын сыйныфында  дәресләр ижат һәм хезмәттәшлек атмосферасында уза; һәр укучы vзен уртак  эшнен бер олеше итеп хис итә. Светлана Равил кызы карашынын тагын бер  моһим олеше - татар теленен мәдәни аспектларын белем бирv процессына  интеграцияләv. Ул дәресләрендә фольклор, музыка һәм традицияләрне  куллана, бу исә укучыларга vз vзенчәлекләрен тирәнрәк анларга һәм

тоярга  момкинлек бирә.
Светлана Равил кызын Мордовия укытучылары яхшы  белә: семинарларда һәм мастер-классларда актив катнашып килә, анда  vзенен казанышлары һәм педагогик алымнары белән уртаклаша. Ул  фикердәшләр бергәлеген бул-дырырга омтыла, анда укытучылар бер-берсен  яна казанышларга ил-һамландыра һәм файдалы идеяләр белән алмаша ала. Бу  педагогларнын индивидуаль vсеше очен генә тvгел, ә мәгариф файдасына  эшләvче барлык педагогик бергәлекне ныгыту очен дә моһим.
Шулай  итеп, Светлана Равил кызы Поташованын конкурста жинvе эшенен әһәмиятен һәм татар теле, әдәбияты һәм мәдәнияте vсешенә керткән олешен  ассызыклый. Без анын кебек педагоглар белән горурланырга тиешбез, алар,  заман таләпләренә карамастан, яна буынны туган телне ойрәнvгә  рухландыруны һәм дәртләндерvне дәвам итәләр. Шундый укытучыларыбыз булуы  татар телен югалтмауга алып бара һәм укытучы – олы исем икәнлеген  дәлилли.

**Наилә НАСЫРОВА**